## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Ялкын авыл җирлеге составына керүче
Ялкын авылы торак пунктында

2020 елның 12 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге составына керүче Ялкын торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Ялкын авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм төзекләндерү;
- янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны яктырту.
3. Әлеге карарны Ялкын авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Ялкын авыл җирлеге башлыгы И.В.Гущина